**МИНИСТЕРСТВО ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ УРМАН ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

20.09.2022 № 495-осн

Казан ш.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2019 елның 26 мартындагы 186-осн номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының Мактау грамотасы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының ведомство бүләкләре турында» 2019 елның 26 мартындагы 186-осн номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының Мактау грамотасы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертеп, 6 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«Министрлык карамагында булган, Мактау грамотасы белән бүләкләнгән дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренә: казна учреждениеләре хезмәткәрләре өчен – бер вазыйфаи оклад күләмендә, бюджет учреждениеләре хезмәткәрләре өчен вазыйфаи окладның 30 проценты күләмендә дәүләт учреждениесенең хезмәткә түләү фонды акчалары хисабына бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк түләнелә.».

2. Юридик бүлек җитәкчесенә (В.В.Мәнихова) имзаланган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек чорда боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр Р.Ә. Кузюров